**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 12 мартындагы 761 номерлы карары**

## Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 1 мартындагы 708 номерлы карары белән расланган Девятаев, Камил Якуб, Мехчылар урамнары чикләрендәге территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү турында

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45 һәм 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына таянып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 1 мартындагы 708 номерлы карары белән расланган Девятаев, Камил Якуб, Мехчылар урамнары чикләрендәге территорияне планлаштыру проектына (Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 24 июлендәге 2341 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), әлеге карарның кушымтасы нигезендә аның аерым өлешләрен раслап, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны, кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалана торган материал) кала, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 12 мартындагы
761 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 1 мартындагы 708 номерлы карары белән расланган Девятаев, Камил Якуб, Мехчылар урамнары чикләрендәге территорияне планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләр**

1. Кызыл линияләр, планлаштыру структурасының элементлары чикләре һәм капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре күрсәтелгән планлаштыру проекты сызымы фрагментын әлеге үзгәрешләргә кушымта нигезендә бирергә.

2. Территорияне план буенча үстерү характеристикалары турындагы нигезләмәдә 3 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3 нче таблица

**Территориядән файдалануның проект балансы**


| № т/б | Күрсәткечләрнең атамасы | Территория мәйданы, га | Территория мәйданы, % |
|---|---|---|---|
| 1 | **Территория** | | |
| | Планлаштыру проекты чикләрендә территориянең мәйданы – барлыгы, шул исәптән | **56,22** | **100,0** |
| 1.1 | **Торак зоналар** | **10,23** | **18,2** |
| | 5 тән 8 катка кадәр булган урта катлы торак төзелеше зонасы | 3,63 | 6,5 |
| | 9 катлы һәм аннан да югарырак катлы булган күпкатлы торак төзелеше зонасы | 2,94 | 5,2 |
| | Гомуми белем бирү мәктәпләре зонасы | 2,17 | 3,9 |
| | Мәктәпкәчә балалар учреждениеләре зонасы | 1,49 | 2,7 |
| 1.2 | **Махсуслаштырылган иҗтимагый төзелеш зонасы** | **11,15** | **19,8** |
| | Иҗтимагый-эшлекле зона | 8,34 | 14,8 |
| | Сәүдә-көнкүреш билгеләнешендәге зона | 0,59 | 1,0 |

| № т/б | Күрсәткечләрнең атамасы | Территория мәйданы, га | Территория мәйданы, % |
|---|---|---|---|
| | Медицина һәм сәламәтлек саклау объектлары урнаштырыла торган махсуслаштырылган зона | 0,15 | 0,3 |
| | Спорт объектлары урнаштырыла торган махсуслаштырылган зона | 0,06 | 0,1 |
| | Гыйбадәт объектлары урнаштырыла торган махсуслаштырылган зона | 1,18 | 2,0 |
| | Мәдәният объектлары урнаштырыла торган махсуслаштырылган зона | 0,07 | 0,1 |
| | Мәгариф объектлары урнаштырыла торган махсуслаштырылган зона | 0,76 | 1,4 |
| 1.3 | **Җитештерү һәм коммуналь-склад зоналары** | **20,66** | **36,7** |
| | Җәмәгать, коммуналь-склад, җитештерү билгеләнешендәге объектлар катнаш урнашкан зона | 12,64 | 22,5 |
| | Җитештерү зонасы | 8,02 | 14,3 |
| 1.4 | **Транспорт һәм инженерлык инфраструктурасы зонасы** | **13,39** | **23,8** |
| | Инженерлык корылмалары, инженерлык инфраструктурасы зонасы | 0,08 | 0,1 |
| | Транспорт инфраструктурасы зонасы | 1,04 | 1,8 |
| | Урам-юл челтәре зонасы | 12,27 | 21,8 |
| 1.5 | **Рекреация зоналары** | **0,63** | **1,1** |
| | Гомуми кулланыштагы яшелләндерелгән территорияләр зонасы | 0,63 | 1,1 |
| 1.6 | **Махсус билгеләнеш зонасы** | **0,16** | **0,3** |
| | Махсус билгеләнештәге яшелләндерү зонасы | 0,16 | 0,3» |

___

I. Фрагмент чертежа проекта планировки с указанием красных линий, границ элементов планировочной структуры и границ зон планируемого размещения объектов капитального строительства

Приложение к изменениям, вносимым в проект планировки территории в границах улиц Девятаева, Камиля Якуба, Меховщиков, утвержденный постановлением Исполнительного комитета г.Казани от 01.03.2024 №708.




**УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ**

- граница проекта планировки территории
- граница элемента планировочной структуры
- граница зоны размещения объектов капитального строительства
- зона размещения существующих объектов общественно-делового назначения

0 20 40 60 80 метры

М 1:1000